ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 89-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 306-VII ДС

89-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2007, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2023, № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның бишенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Законның гамәли көче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә торган Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела торган Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлегенә кагылмый. Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлегенең оештыру һәм хокукый нигезләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

2) 6 статьяда «федераль дәүләт хакимияте органнары» сүзләреннән соң «, Мәскәү шәһәре дәүләт хакимияте органнары һәм Мәскәү өлкәсе дәүләт хакимияте органнары, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының Мәскәү шәһәрендә урнашкан вәкиллекләре, чит дәүләтләр вәкиллекләре һәм миссияләре, халыкара оешмалар, чит ил компанияләре, иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяның дүртенче өлешендә «йә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 11 статьяда:

а) 6 пунктта «Татарстан Республикасы турында» сүзләрен «, Татарстан Республикасына кагылышлы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта «Татарстан Республикасы предприятиеләре, оешмалары, иҗтимагый берләшмәләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр» сүзләренә, «чит дәүләтләрнең, чит федератив дәүләтләр субъектларының, чит дәүләтләрнең административ-территория берәмлекләренең һәм Россия Федерациясе субъектларының предприятиеләре, оешмалары, иҗтимагый берләшмәләре» сүзләрен «чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территория берәмлекләре һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

5) 12 статьяның өченче өлешендәге 4 пунктында «хезмәткәрләрен» сүзен «эшчеләрен» сүзенә алмаштырырга;

6) 15 статьяның икенче өлешендә «юкка чыгару» сүзләрен «бетерү» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – Закон) федераль һәм республика законнары беләнт тәңгәлләштерү максатларында эшләнде.

Законның 1 статьясы нигезендә Законның гамәлдә булуы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт учреждениесе яисә коммерциягә карамаган башка оешма рәвешендә төзелә торган сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләренә кагылмый.

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 52 статьясы нигезендә юридик затлар аларны гамәлгә куючылар раслый торган уставлар нигезендә эш итә. Билгеләнгән нормадан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелгән сәүдә-икътисадый вәкиллекләр уставлар нигезендә эш итәргә тиеш. Шул ук вакытта бүгенге көндә Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый вәкиллекләре алар турындагы нигезләмәләр нигезендә эш итәләр.

Закон проекты тиешле үзгәрешләрне күздә тота. Проектлана торган нигезләмәләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлеген оештыру һәм аның хокукый нигезләрен билгеләү хокукы карала. Әлеге норма Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый вәкиллекләрен һәм вәкилләрен гамәлгә кую һәм аларның эшләү вариантларын җайга салу мөмкинлеген бирәчәк.

Башка үзгәрешләр аерым нигезләмәләрнең актуальләшүе белән бәйле.

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

**«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Ханты-Манси автономияле округында сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2001 елның 5 маендагы 257 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Түбән Новгород өлкәсендә сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2001 елның 17 октябрендәге 767 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Саратов өлкәсендә сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2002 елның 18 июнендәге 345 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Швейцария Конфедерациясендә сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2002 елның 19 сентябрендәге 547 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый вәкиллекләре турында» 2006 елның 2 августындагы 399 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дубайда (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2013 елның 30 маендагы 364 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кытай Халык Республикасында сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2014 елның 1 октябрендәге 707 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Германия Федератив Республикасында сәүдә-икътисадый вәкиллеген оештыру турында» 2019 елның 3 августындагы 641 номерлы карары.